| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Менделеевский муниципальный район<br>Глава Мунайкинского сельского поселения | Татарстан Республикасы<br>Менделевск муниципаль районы<br>Монай авыл җирлеге башлыгы |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№3 18.11.2024 ел

Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлегенең
Монай торак тунктында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге башлыгы КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 28 ноябре 16.00 сәг. ТР, Менделеевск муниципаль районы, Монай т.п. Төзүчеләр урамы, 12 йорт адресы буенча урнашкан Монай авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай т.п. гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. 2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы тыл веҗераннарыннан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы" дигән сорауны расларга.

«1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (авыл эчендәге юлларны ремонтлау (Төзүчеләр, Төньяк, Йолдыз, Ленин урамнарына вак таш түшәү, Төзүчеләр, Монтажчылар урамындагы юл өслегендә булган чокырлар ремонтлау).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Монай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып халыкка җиткерергә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru "Монай авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Монай  авыл җирлеге башлыгы  ______________  Р.М.Кириллов

(имза)  (имзаның аңлатмасы)